КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 28 декабрь г.Казань № 1232

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе Музей фонды торышын төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тоту турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 30 сентябрь, 937 нче карары белән расланган Россия Федерациясе Музей фонды торышын төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тоту турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе Музей фонды торышын төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тоту турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 30 сентябрь, 937 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 26 февраль, 167 нче, 2022 ел, 24 октябрь, 1135 нче, 2023 ел, 5 сентябрь, 1074 нче, 2023 ел, 02 ноябрь, 1411 нче, 2024 ел, 6 июль, 530 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Россия Федерациясе Музей фонды торышын төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тоту турындагы нигезләмәгә, 17.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәп, үзгәреш кертергә:

«контрольдә тотыла торган затның төп фондының экспонат музей предметларын алдагы ел белән чагыштырганда 5 процентка һәм аннан да күбрәк кыскарту («Музей эшчәнлеге турында мәгълүматлар» 8-НК номерлы федераль статистик күзәтү формасының мәгълүматлары нигезендә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин